ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 август 2025ел № 6137

Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8504 номерлы Карары белән расланган муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлеше үз көчен югалтуны тану хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясының 5 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8504 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 16 ноябрендәге 11194 номерлы, 2024 елның 5 сентябрендәге 5727 номерлы, 2025 елның 30 гыйнварындагы 556 номерлы, 2025 елның 30 гыйнварындагы 557 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.8.2.1 пунктының 13 пунктчасына, «басылып чыккан һәм» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов